ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НИЖНЕКАМСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. Строителей, д.12, г. Нижнекамск, 423570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТҮБӘН КАМА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Төзүчеләр пр., 12 нче йорт, Түбән Кама шәһәре, 423570

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06 12 2024 г. № 1281

Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 27 сентябрендәге 1376 номерлы карары белән расланган белем бирү оешмасына йөрүче, мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы балаларга компенсация түләүләре бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме, башка социаль гарантияләр һәм түләүләр кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм) чараларын билгеләү һәм күрсәтү процессларын гамәлгә ашыруга төп таләпләрне раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 564 номерлы карары нигезендә Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 27 сентябрендәге 1376 номерлы карары белән расланган мәктәпкәчә белем бирү программасын гамәлгә ашыручы мәгариф оешмаларына йөрүче балалары булган гражданнарга компенсация түләүләре бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 2.9 пункт өстәргә:

«2.9. Техник мөмкинлек булганда компенсация бирү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль хезмәт күрсәтү һәм дәүләт социаль ярдәме кысаларында күрсәтелә торган социаль яклау (ярдәм), социаль хезмәт күрсәтү чараларын билгеләү һәм күрсәтү процессларын гамәлгә ашыруга төп таләпләрне, башка социаль гарантияләрне һәм түләүләрне раслау турында» 2024 елның 3 маендагы 564 номерлы карары нигезендә электрон рәвештә башкарыла.

Күрсәтелгән очракларда компенсация «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасыннан яисә дәүләт хакимияте органнарының (дәүләт органнары), җирле үзидарә органнарының, Россия Федерациясенең пенсия һәм социаль страхование фондының, шулай ук дәүләт

хакимияте органнары һәм җирле үзидарә органнары карамагындагы оешмалардан файдаланып бирелә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Түбән Кама муниципаль районы Башкарма комитеты рәисе урынбасары И.И. Рамазановка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Булатов